**СОВЕТ СЕЛО-АЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422721, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алат, ул.Первомайская, 32

422721, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алат авылы, Первомай урамы, 32

тел./факс 8(84365) 63-2-25, e-mail:Salat.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**17 июня 2024 г.** **№ 95**

## Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Алат авыл җирлеге Советы:

Карар кабул итте:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада физик затларның бурычы булуы.

2. Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында

белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. Алат авыл җирлеге Советының 2023 елның 21 июнендәге 80 номерлы «җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Алат авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хакимуллин